**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"17" ноябрь 2023 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз сум) күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

Бахтияр авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм чистарту);

Урам яктырту хезмәте (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру өчен материаллар сатып алу);

Бахтияр авылында балалар өчен уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Бахтияр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Мәңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Филатова Ф.Ф.